**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ УРЫССУ БИСТӘСЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

«_02_» _02_2026 ел Урыссу штб № __1__

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе Советының 18.05.2018 № 10 карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе муниципаль хезмәткәрләренең, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ санлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 12.02.2009 ел, №15-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, "Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында" 28.03.2018 ел, № 182 карарына үзгәрешләр кертү хакында"гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 25.11.2025 № 994 карары нигезендә, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе Советының 18.05.2018 № 10 карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә (алга таба – нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1 бүлегенең 1 пунктында «15 389» саннарын «16 928» саннарына алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районының "Урыссу
шәһәр тибындагы бистәсе" муниципаль
берәмлеге Советы Рәисе,
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районының
шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе
Башлыгы А.Ә. Шәфигуллин